# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Су кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

**1 статья.** Татарстан Республикасы Су кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 9) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. Преамбулада «Татарстан Республикасы халкының байлыгы» сүзләрен «халык тормышы һәм эшчәнлеге нигезе» сүзләренә алмаштырырга.

2. 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу федераль законнар, әлеге Кодекс һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге бүтән норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.».

3. 4 статьяның алтынчы өлешендә «әлеге Кодекста» сүзләрен «Россия Федерациясе Су кодексында» сүзләренә алмаштырырга.

4. 6 статьяның икенче абзацын төшереп калдырырга.

5. 7 статьяның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«республика милкендәге эчәр сулар белән тәэмин итү чыганакларын резервлау;».

6. 8 статьяның икенче өлешендәге дүртенче-алтынчы абзацларын төшереп калдырырга.

233

7. 9 статьяның икенче өлешендәге икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«республика милкендәге һәм җирле администрация карамагыиа тапшырылган аерымланган су объектларына законнарда билгеләнгән тәртиптә идарә итү һәм алар белән эш итү;».

8. 14 статьяның икенче өлешендә, 15 статьяның икенче өлешендә, 17 статьяның алтынчы һәм җиденче өлешләрендә, 21 статьяның икенче өлешендә, 29 статьяның беренче һәм өченче өлешләрендә, 30 статьяның өченче өлешендә, 33 статьяның беренче өлешендә, 71 статьяның өченче өлешендә «әлеге Кодекста» сүзләрен «федераль законнарда» сүзләренә алмаштырырга.

9. 14 статьяда:

өченче һәм дүртенче өлешләрдә «су» сүзен төшереп калдырырга;

бишенче өлештә «милекче ризалыгы белән» һәм «яисә, милекче үзе хәл итсә генә,» сүзләрен төшереп калдырырга.

10. 16 статьяда:

беренче өлештә «аерымланган су объектларыннан гайре, дәүләт милкендәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Су объектларыннан файдалану хокуклары бер заттан икенче затка бары тик законнар нигезендә бирелә торган эш итү лицензиясе буенча гына күчәргә мөмкин.».

11. 17 статьяда:

беренче өлештә:

түбәндәге редакциядә икенче яңа абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе;»;

икенче-бишенче абзацларны өченче-алтынчы абзацлар дип санарга;

икенче өлештә «әлеге Кодекста» сүзләрен «законнарда» сүзенә алмаштырырга.

12.IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV бүлек. **Су объектларына милекчелек хокукы**

18 статья. **Су объектларына карата милек рәвешләре**

Татарстан Республикасында су объектларына дәүләт милке федераль законнар нигезендә билгеләнә.

Җирле үзидарә милке һәм хосусый милек бары тик аерымланган су объектларына гына рөхсәт ителә.

234

**19 статья. Су объектларына Татарстан Республикасының милекчелек хокукы**

Татарстан Республикасы милкендә (республика милкендә) акваторияләре һәм бассейннары тулысынча Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан һәм федераль милеккә кертелмәгән су объектлары булырга мөмкин.

Су объектларын Татарстан Республикасы милкенә кертү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы милкендәге су объектларына идарә итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы гамәлгә ашыра.

Күрсәтелгән су объектлары милкенә идарә итү буенча вәкаләтләрнең бер өлеше федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарма хакимиятнең тиешле федераль органнарына тапшырылырга мөмкин.

**20 статья. Аерымланган су объектларына җирле үзидарәнең милек хокукы һәм хосусый милек хокукы**

Җирле үзидарә милкендә җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен билгеләнгән аерымланган су объектлары булырга мөмкин. Җирле үзидарә исеменнән милекче хокукын җирле үзидарәнең тиешле органнары гамәлгә ашыра.

Гражданнар һәм юридик затлар милкендә аерымланган су объектлары (йомык сулыклар) - башка су өсте объектлары белән гидравлик бәйләнештә тормаучы, мәйданы буенча зур булмаган һәм агып чыкмый торган ясалма сулыклар булырга мөмкин.

Аерымланган су объектларының иң чик күләмнәре җир турындагы законнар белән билгеләнә.».

13. 21 статьяның өченче өлешендә «әлеге Кодекста» сүзләрен «федераль законда» сүзләренә алмаштырырга.

14. 23 статьяның дүртенче өлешендә «әлеге Кодекс» сүзләрен «Россия Федерациясе Су кодексы» сүзләренә алмаштырырга.

15. 26 статьяда:

беренче өлештә «Әгәр әлеге Кодекста башкасы каралмаган булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус файдалану режимы билгеләнгәндә җир өсте су объектларыннан файдалану хокукы федераль законнар нигезендә алына.»;

өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Судан файдаланучы граждан үлгән, судан файдаланучы юридик зат үзгәртеп корылган очракта, аларның су объектларыннан файдалану хокуклары хокук дәвамчылыгы тәртибендә көчә.»;

бишенче өлештә «әлеге Кодекста» сүзләрен «су турындагы законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гомуми су сервитутыннан гайре, җир өсте су объектларыннан файдалану хокуклары су объектыннан файдалану шартнамәсе дәүләт тарафыннан теркәлгән мизгелдән барлыкка килә.»;

җиденче өлешне төшереп калдырырга.

16. 27 статьяның дүртенче өлешен төшереп калдырырга.

17. 33 статьяның беренче өлешендәге бишенче абзацында «бетерелсә» сүзен «эшчәнлеге туктатылса» сүзләренә алмаштырырга.

18. 34 статьяда:

дүртенче өлештә «граждан законнары» сүзләрен «федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус файдалануга тапшырылган су объектларыннан файдалану хокукларын туктату федераль законнар нигезендә башкарыла.».

19. 35 статьяда «әлеге Кодекста һәм башка» сүзләрен «федераль» сүзенә алмаштырырга.

20. 37 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Су объектларын махсус файдалануга тапшыру тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

21. 38 статьяда:

икенче өлештә «Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарәнең тиешле органнары белән килештереп» сүзләрен «Җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә милкендәге һәм хосусый милектәге аерымланган су объектларында судан гомуми файдалану, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп, милекче билгеләгән шартларда законнар нигезендә рөхсәт ителә. Аерымланган су объекты милекчесе судан гомуми файдалану шартлары яисә аны тыю турында игълан итәргә тиеш.».

236

22. 39 статьяның дүртенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Судан файдалану (су куллану һәм су җыю) лимитларын яңадан карау тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

23. 41 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органының җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау буенча дәүләт идарә органы белән, табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән, санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт органы һәм балык ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау идарәсе органы белән килештерелгән тәкъдиме буенча су объектларыннан файдалануны чикләүне, туктатып торуны яисә тыюны билгеләргә хокуклы.».

24. 45 статьяда:
дүртенче өлештә «Әлеге статьяның 5 өлешендә» сүзләрен «законнарда» сүзенә алмаштырырга;
алтынчы өлештә «торуны санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт органы гамәлгә ашыра» сүзләрен «тору законнар нигезендә гамәлгә ашырыла» сүзләренә алмаштырырга.

25. 47 статьяның икенче өлешендә «һәм җир асты байлыклары турындагы законнар» сүзләрен төшереп калдырырга.

26. 48 статьяның икенче өлешендә «, дәүләт экология һәм санитария-эпидемиология экспертизасының уңай бәяләмәсе булганда һәм бу тиешле территориянең курорт-рекреация потенциалына зыян китермәсә генә,» сүзләрен төшереп калдырырга.

27. 51 статьяның икенче өлешендә «гидротехник» сүзеннән соң «һәм гидроэнергетик» сүзләрен өстәргә.

28. 52 статьяда:
икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты суднолар йөртү, сал агызу өчен файдаланыла торган, һава суднолары очып китү (очып төшү) өчен яраклы булган су объектларының исемлеген билгеләүдә федераль законнар нигезендә катнаша.»;
дүртенче өлештә «тәртиптә» сүзеннән соң «законнар нигезендә» дип өстәргә.

29. 53 статьяда:

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты балык ресурсларын һәм башка биоресурсларны саклау, торгызу һәм чыгару өчен билгеләнгән су объектларының яисә аларның участокларының исемлеген билгеләүдә федераль законнар нигезендә катнаша.»;

бишенче өлештә «законнар» сүзе алдыннан «федераль» дип өстәргә.

30. 54 статьяда «су турындагы законнар һәм хайваннар дөньясын саклау, аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнар» сүзләрен «законнар» сүзенә алмаштырырга.

31. 55 статьяның беренче өлешендә «дәүләт идарәсенең җирле органнары яисә» сүзләрен төшереп калдырырга.

32. Закон текстында «әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы» һәм «әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы» сүзләрен тиешле килешләрдә һәм саннарда «табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы» сүзләренә алмаштырырга.

33. 57 статьяның беренче өлешендә «Җир асты байлыклары турындагы Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Кодекс» сүзләрен төшереп калдырып, «законнар» дип язарга.

34. 62 статьяның өченче өлешендә «, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы» сүзләрен төшереп калдырырга.

35. 64 статьяда:

дүртенче өлештә «әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы өлешнең бишенче абзацында «һәм ясалма су объектларын, шул исәптән аерымланган су объектларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны файдалануга кертүне тыю турында федераль законнар нигезендә карарлар кабул итәргә хокуклы.».

36. 66 статьяда:

икенче өлештә «һәм табигый дәвалау ресурсларыннан торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче өлештә «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы өлештә «дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдалы казылмалар чыгарганда, су киметү эшләрен башкарганда, корылмалар төзегәндә яисә суларның зарарлы йогынтысыннан сакланганда, шулай ук сугарылган җирләрдә дренаж системалары төзегәндә һәм алардан файдаланганда җир асты суларын аерып алу судан файдалануга лицензия булганда гына рөхсәт ителә.».

37. 67 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

38. 69 статьяның өченче өлешендәге өченче абзацында «, бу чакта су объектларындагы зарарлы матдәләрнең иң чик мөмкин концентрацияләрен арттыру рөхсәт ителми» сүзләрен тәшереп калдырырга.

39. 70 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир өсте суларын агызуның һәм аларны бөтенләй юк итүнең иң чик мәмкин күләмнәре су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, табигый ресурслардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан федераль законнарда каралган тәртиптә һәр су объекты өчен аерым билгеләнә.».

40. 71 статьяда:

бишенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Су саклау зоналарының, яр буе саклау полосаларының үлчәмнәрен һәм чикләрен билгеләү тәртибе, шулай ук алардан файдалану режимы федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

алтынчы өлештә «хуҗалык сулары һәм эчәр сулар» сүзләрен «эчәр сулар» сүзләренә алмаштырырга.

41. 72 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«72 статья. **Су саклау зоналарындагы җир кишәрлекләрен файдалануга тапшыру үзенчәлекләре һәм алардан файдалануны тикшереп тору**

Су объектларының су саклау зоналарындагы җир кишәрлекләре физик һәм юридик затларга, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау

өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп, җир турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә.».

42. 74 статьяның икенче өлешен төшереп калдырырга.

43. 77 статьяда:
икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Суларның зарарлы йогынтысын кисәтү һәм килгән зыянны бетерү буенча кичектергесез чаралар күрүне оештыру федераль законнар нигезендә төзелүче ташуга каршы һәм бүтән махсус комиссияләр тарафыннан башкарылырга мөмкин. Бу комиссияләрнең үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарларын дәүләт идарәсенең барлык органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар үтәргә тиеш.»;
оченче өлештә «дәүләт идарәсенең җирле органнары,» сүзләрен төшереп калдырырга.

44. 82 статьяның дүртенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Су ресурсларыннан комплекслы файдалану һәм аларны саклау схемаларын эшләү, килештерү, аларга дәүләт экспертизасы ясау, аларны раслау һәм гамәлгә ашыру тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

45. 83 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«83 статья. **Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә республика программалары**

Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге гамәлләрне планлаштыру өчен су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә республика программалары эшләнә.
Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә республика программаларын эшләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

46. 84 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Су объектларының дәүләт мониторингы әйләнә-тирә табигать мохите мониторингы бердәм системасының состав өлешен тәшкил итә һәм законнар нигезендә алып барыла.».

47. 87 статьяның дүртенче һәм бишенче өлешләрен төшереп калдырырга.

48. 90 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «законнарда» сүзенә алмаштырырга.

240

49. 92 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«92 статья. **Судан файдалануның түләүле булуы**

Су объектларыннан файдалану, федераль законда каралган очраклардан гайре, түләүле була.

Су объектларыннан файдалануга бәйле түләүне билгеләү һәм аны алу тәртибе, аның күләмнәре законнар белән билгеләнә.».

50. 93, 94, 95 статьяларны төшереп калдырырга.

51. 101 статьяда:

өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Су турындагы законнарны бозу аркасында су объектларына китерелгән зыянны түләтү турындагы дәгъваларны су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, табигый ресурслардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органнары, санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт органы федераль законнар нигезендә белдерергә хокуклы.»;

дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Суд карары буенча алынучы зыян түләү суммалары билгеләнгән тәртиптә федераль бюджетка яисә Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә һәм су объектларын торгызу очен җибәрелә.».

52. XIV бүлекне төшереп калдырырга.

**2 статья**. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 21 ноябре
№ 1192